| | |
|---|---|
| **Укытучы** | **Лизунина Эльвира Хәмзә кызы** |
| **Предмет** | **Татар теле, 5 нче сыйныф** |
| **Тема** | **“Мин өйдә булышчы” темасы буенча кабатлау.** |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр** | **Шәхескә кагылышлы: Татар теленә карата кызыксыну булдыру, уңышка ирешү дәрәҗәсен аңлау**<br>**Метапредмет:**<br>***Танып-белү УУГ:***<br>- куелган мәсьәләне чишүдә алгоритмны куллана белү;<br>- телдән сөйләмдә үз фикерләреңне формалаштыра белү;<br>- өлешләрдән бербөтенне төзи белү;<br>- гомумиләштерү.<br>***Коммуникатив УУГ:***<br>- сөйләмнең диалогик формасы белән эш итә белү;<br>- хезмәттәшлектә башкаларның фикерләрен исәптә тоту һәм карашыңны яклый белү;<br>- үз фикереңне һәм карашыңны формалаштыру;<br>- бердәм эшчәнлектә уртак нәтиҗәгә килү.<br>***Регулятив УУГ:***<br>- уку мәсьәләсен кабул итү һәм дәрес дәвамында шуның буенча эшләү;<br>- куелган мәсьәлә нигезендә үз эшчәнлегеңне планлаштыру.<br>**Предмет буенча:** өйрәнелгән лексик-грамматик конструкцияләрне, фигыль формаларын (хикәя, боерык, инфинитив) сөйләмдә куллана белүне камилләштерү, алар белән сүзтезмәләр, җөмләләр төзи алу. |
| **Дәреснең тибы** | диалолик-монологик сөйләмгә чыгу, йомгаклау дәресе |
| **Төп төшенчәләр** | хикәя, боерык, инфинитив фигыльләр |
| **Предметара бәй-ш** | әдәбият, рус теле, әйләнә-тирәне өйрәнү |
| **Эшне оештыру** | Фронталь, төркемдә, парларда, индивидуаль |
| **Чыганаклар** | Дәреслек, презентация, карточкалар, рәсемнәр, ял итү минуты өчен музыка,компьютер, проектор. |

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **Универсаль уку гамәлләре (УУГ)** |
|---|---|---|---|
| **Оештыру**<br>**Мотивлаштыру**<br>**(1-2 мин)** | 1. Уңай психологик халәт яки эш атмосферасы тудыра.<br>2. Укытучы балалар белән исәнләшә. (әңгәмә үткәрә)<br>- Хәерле көн!<br>- Хәерле көн, миңа!<br>- Хәерле көн, сиңа!<br><br>- Хәерле көн, сезгә!<br>- Хәерле көн, барыбызга да! | Сыйныф эшкә әзерләнә (укытучыны сәламлиләр, бергә хәрәкәтләр ясыйлар, сөйләм эшчәнлегенә кушылалар)<br>Кул изиләр<br>Үзләренә күрсәтәләр<br>Бер-берсенең кулларына кулларын куялар<br>Кулларны җәяләр<br>Кул бирәләр. | Ш –үзмаксат кую;<br>К – сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген ештыруда хезмәттәшлек тү;<br>Р – үзбәя; фаразлау |
| **Белемнәрне актуальләштерү. Дәрес темасын ачыклау.** | Видео (рәсемле җыр) “Мин әнигә булышам: савыт – саба юышам, гөлләргә су сибәм, идән юышам. | Сорауларга җавап бирәләр.<br>- Малай һәм кыз нишли?<br>- Сез өйдә булышасызмы? Нәрсә эшлисез? | Ш – эшләп карау, эш-гамәлләрдә үз-үзеңне сынау.<br>К – башкаларның сөйләмен тыңлау, аңлау, дөрес әйтелеш өчтендә эшләү.<br>Р –үзконтроль<br>(Хәзерге заман хикәя фигыль формасы кабатлана) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Белемнәрне формалаштыру, ныгыту** | 1. Бирелгән фигыльләрне хщзерге, үткән заманда әйтү.<br>2. Билгесез үткән заманда әйтү.<br>3. Укучылар төрле предметлар ярдәмендә нинди эш эшләгәннәрен күрсәтә. Калган укучылар аларга эш эшләргә булыша. (боерык фигыль, инфинитив кабатлана) | Кабатлыйлар, сорауларга җавап бирәләр<br><br>(Идән юган – идән юмаган)<br>Кемгә булышабыз?(әнигә, этигә, бабайга, әбигә)<br>Наил нишли? – Гөлләргә су сибә.(Гөлләргә су сибәргә булыш.)<br>Радель нишли? Күлмәк үтүкли. (Күлмәк үтүкләргә булыш.)<br>Данил нишли? – Машина юа. (Машина юарга булыш.) | ТБ – Үрнәк буенча эшләү, чагыштыру, анализлау<br>Р – хаталарны төзәтү, эшнең нәтиҗәсен бәяләү.<br>П – сүзләрне дөрес итеп әйтү |
| **Диалогик сөйләм күнекмәләрен камилләштерү** | Балаларга конверт бирелә(2 группага)<br>- Укучылар, без хәзер әнигә булышабыз. Әни кем була? Бу конвертта рәсемнәр, әни хәзер үзенә эш сайлый һәм калганнарга да эш бүлеп бирә. | 1. “Эш бүлешү”<br>2. Укытучы сораулар бирә.<br>Әни нишли? Балалар нишли? Оксана нишли? Влада идән юамы? (Әйе, юа. ЯКИ – Юк юмый)Һ.б.<br>3.Укучылар бер – берсенә дә сораулар бирә. (Син нишлисең? | Ш- бер-береңне тыңлый белү.<br>ТБ- рәсемнәр буенча эшләү.<br>К- сыйныфташлар, укытучы белән эшчәнлекне оештыра белү, башкаларның сөйләмен тыңлый, аңлый белү.<br>Р – бәяләү, уку мәсьәләсен дөрес аңлауны бәяләү, планлаштыру. |
| **Ял минуты** | “Күрсәт әле үскәнем” җырына төрле хәрәкәтләр күрсәтелә.<br>- Күрсәт әле үскәнем, ничек идән юалар?<br>- Менә шулай, менә шулай, шулай идән юалар.(һ.б.) | Музыка астында җырлап күнегүләр эшлиләр (өйрәнелгән сүзләр кабатлана) | Р - үзрегуляция |
| **Монологик сөйләмне камилләштерү** | Макет нигезендә рәсемнәр буенча эшләгән эшләрне язалар, аннан сон зур җөмләгә чыгалар. | Рәсемнәр нигезендә укучылар җөмләләр төзи. Бер-берсе белән мәгълүмат алышалар. Һәр төркемнән бер укучы, эшләрне берләштереп, бер зур җөмлә укый. | ТБ –аңлап, иркекле сөйләм төзи белү.<br>К- монологик сөйләм төзи белү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Рефлексия** | Афәрин, укучылар! Хәзер дәресне тәмамлап сыйныфтан чыгарга кирәк. Ләкин ишек ачылсын өчен бүлмәне җыештырырга кирәк.(биремнәр үтәү)<br><br>Сез булдырасыз! Без булдырабыз! Укытучы балаларга сертификатлар тарата.(кушымта 3) | https://joyteka.com/100499421 платформасындагы уен аша дәрестә кабатлаган материалны ныгыту. | Ш- эшчәнлекнең максаты һәм нәтиҗәсе арасында бәйләнешне бәяләү, үзуңыш һәм уңышсызлыкларның сәбәпләрен ачыклау.<br>К- үз фикереңне дәлилли белү, сорауларга җавап бирү.<br>Р- үзбәя. |